Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Кадыровского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Молодежная , д. 1, с. Кадырово,
Заинский район, 423513

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
Башкарма комитеты

Яшьләр урамы, 1 нче йорт, Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**01.02.2024** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» 2024 елның 23 январендәге 46 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Кадер авыл җирлегенең Башкарма комитеты

## карар бирә:

1. 2024 елның 01 февраленнән Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 8370,20 сум күләмендә, 1-нче һәм 2-нче кушымталар нигезендә, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" 2023 елның 03 февралендәге 4 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 февраленнән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Л.Н. Барсукова**

Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
башкарма комитетының
01.02.2024 ел
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2024 елның 01 февраленнән**
**Кадер авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре**

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3183,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1360,74 |
| 4. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3825,86 |
| Барысы | 8370,20 |

Зәй муниципаль районы
Кадер авыл җирлеге
башкарма комитетының
01.02.2024ел
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

**2024 елның 01 февраленнән**
**Кадер авыл җирлегендә мәетне җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре**

| **Хезмәт күрсәтүләрнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүләрнең бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәетне җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 872,95 |
| 3. Мәетне җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2375,87 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (җәсәден) зиратка илтү | 1328,21 |
| 5. Мәетне җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3793,17 |
| Барысы | 8370,20 |